ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 63 от «18» 02 2021 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш районы территориясендә бинаны, торак урынны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт, торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссия турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы «Торак урынны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында» 47 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының 2019 елның 25 июлендәге 202 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш районы территориясендә бинаны, торак урынны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт, торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссия турындагы Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 1.4 пункт өстәргә:

Ведомствоара комиссия карарын кабул итү тәртибе, кабул ителә торган документлар төрләре һәм аларны рәсмиләштерү сроклары Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының аерым норматив хокукый актлары белән билгеләнә («Татарстан Республикасы Мамадыш районы территориясендә бинаны, торак урынны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт, торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссия турындагы Нигезләмәне» раслаучы 2011 елның 3 февралендәге 125 нче карар, «Татарстан Республикасы Мамадыш районы территориясендә бинаны, торак урынны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм

0000010759

күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт, торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын» раслаучы 2019 елның 25 июлендәге 203 нче карары).

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми mamadysh.tatarstan.ru сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М. Никифоровка йөкләргә.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов